## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кызыл Уракчы авыл торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2025 елның 27 октябрендәге 2 номерлы**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кызыл Уракчы авыл торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кызыл Уракчы авыл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган,МХО да катнашучы гражданнардан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта Зирекле авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә. »

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Зирекле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка

житкерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr:/ / pravo. tatarstan .ru)бастырып чыгарырга .

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районы Зирекле
авыл җирлеге Башлыгы Зиннәтуллин А.Р.